| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 07.11.2025 ел, | с. Шеланга | № 2-29 |

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясе өлешендә үзара салым кертү һәм аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы 28.07.2004 ел №45-3 номерлы законының 35ст. , Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 нче елның 18 нче ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылы территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 240 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

урамнарны яктыртуны оештыру;

| | |
|---|---|
| «ӘЙЕ» | «ЮК» |

3. Гражданнар җыенын 18.11.2025 ел Шилангы авылы, Төзүчеләр урамы адресы буенча, 3 йорт янында 16.45 сәгатьтә уздырырга.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров